Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче Биклән авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче Биклән авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 20 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-урам яктырту эшләрен башкару;

-Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү».

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 20 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Биклән авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-урам яктырту эшләрен башкару;

-Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Биклән авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш. Сәхбеев